КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 май г.Казань № 627

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 июль, 511 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 948 нче; 2016 ел, 4 июль, 457 нче; 2019 ел, 25 июнь, 512 нче; 2021 ел, 21 декабрь, 1261 нче; 2023 ел, 18 гыйнвар, 21 нче; 2023 ел, 30 март, 378 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибендә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «яңаларын билгели, үзгәреш кертә яки гамәлдән чыгара торган» сүзләрен «яңаларын билгели яки үзгәреш кертә торган» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «яңаларын билгели, үзгәреш кертә яки гамәлдән чыгара торган» сүзләрен «яңаларын билгели яки үзгәреш кертә торган» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасының беренче абзацында «яңаларын билгели, үзгәреш кертә яки гамәлдән чыгара торган» сүзләрен «яңаларын билгели яки үзгәреш кертә торган» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның 3 пунктчасындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) гадәттән тыш аерым хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда һәм (яки) килеп чыкканда, әзерлек югары дәрәҗәдә булу, гадәттән тыш хәл режимын керткәндә кабул ителергә тиешле яки «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы федераль конституция законы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында кертелә торган махсус режимнар кысаларында күрелә торган чараларны башкару максатларында эшләнелә торган.»;

1.3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җайга салучы орган – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле өлкәдә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы;»;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның 3.2.10 пунктчасының икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

3.3.4 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.11 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4.12 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актларының һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү буенча эксперт советы турындагы нигезләмәдә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Беренче этапта республика башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы норматив хокук актларының һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрүгә вәкаләт бирелгән республика башкарма хакимият органына (алга таба – Вәкаләтле орган) аларны Эксперт советының беренче составына кертү өчен кандидатуралар турында тәкъдимнәр бирә. Кандидатуралар турындагы тәкъдимнәр әлеге Нигезләмәгә теркәлә торган республика башкарма хакимият органнары функцияләре нигезендә җибәрелә. Тәкъдимнәрдә югарыда күрсәтеп үтелгән һәр функция буенча кимендә бер эксперт булырга тиеш.»;

дүртенче абзацта тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен тиешле килешләрдәге «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

8 пунктның «Дәүләт идарәсе функциясе исеме» графасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

31 пунктның «Дәүләт идарәсе функциясе исеме» графасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин